ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 26 октябре** **Чистай шәһәре** **№ 638**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Башкарма комитетының
2020 елның 27 мартындагы 159 номерлы карары
белән расланган Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы территориясендә
гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда
җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны
саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга
бәйле җир асты корылмаларын төзегәндә муниципаль
контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр
үткәрүнең административ регламентын раслау турында.

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 5 статьясы, «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 мартындагы 159 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануга һәм аларны саклауга, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле җир асты корылмаларын төзегәндә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов